| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.02.2023 Казан ш № 114

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 5 февралендәге 55 номерлы, 2022 елның 5 мартындагы 164 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән

үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның «22» февралендәге 114 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

2.4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.13 пунктның беренче һәм өченче абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.13 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тест уздыру Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тест уздыру методикасына ярашлы рәвештә башкарыла».